


**Фатыйхова, Эльвира**
**«Бер шаман: «бу юл турыда китап язарсың», - диде...» / Э. Фатыйхова; [әңгәмәдәш] А. Сәлахова // Идел. – 2020. – № 9 (372). – С. 38-39: фото.**

**Фатыйхова, Эльвира**
**Шаманнар артыннан сәяхәт: китаптан өзек / Э. Фатыйхова // Идел. – 2020. – № 9 (372). – С. 40-48: фото.**
**http://idel-tat.ru/news/literatura-tt/shamannar-artynnan-syakht**

Журналист Эльвира Фатыйхова нон-фикшн жанрында татарча китап чыгарды. Исеме дә кызыклы: «Шаманнар артыннан сәяхәт». Бу – Эльвираның беренче китабы. Басма - сәяхәтләрдән көндәлек форматында. Ул авторның Хакасия, Тыва, Казакъстан, Кыргызстан якларына сәяхәтләре турында. «Идел» журналының 2020 елгы 9нчы санында Алсу Сәлахованың Эльвира Фатыйхова белән китап хакында әңгәмәсе басылды.




Шулай ук «Идел» журналының әлеге санында «Шаманнар артыннан сәяхәт» китабыннан өзек тә укый аласыз.

*« – Кеше белән табигать гармониядә яшәргә тиеш. Син табигатькә хөрмәт күрсәтсәң генә, шул җир иясе сиңа табыш, мал китерә. Мәсәлән, сулыклар янында хаҗәтләреңне башкарырга ярамый. Кимендә, чыганаклар сиңа сәламәтлек бирмәячәк яисә, бу гамәлеңә ачуланып, чир китерәчәк. Аучылыкның да табигатькә зыян салмый торган үз кануннары бар. Әйтик, балалы хайваннарны атарга ярамый. Югыйсә үз балаңа, гаиләңә зур зыян киләчәк. Электән килгән гадәт бар: аучы үз табышын авылдагы һәркем белән бүлешкән. Һичьюгы, һәркем ул ризыктан, аз гына булса да, авыз иткән. Хәзер дә бүлешү дигән төшенчә бар. Син үзең генә табигый байлыклардан файдалана алмыйсың, кемнәрнедер сыйлыйсың, хәйрия белән шөгыльләнәсең, – диде Айдын Чылбаевич һәм тагын әллә нинди буддистлык кануннарын санады. Ул бу гадәтләрнең күбесенчә шаманлыктан булуын да аңлый, мин дә тел төбен төшенәм, ләкин икебезнең беребез дә сер бирми... Шаманлык белән буддизм симбиозы биредәге бәйрәмнәрдә бигрәк тә ачык күренә. Мәсәлән, Шагаада, ягъни тываларның Яңа ел бәйрәмендә, Сан-Сарылы дигән йола уздырыла икән. Анда буддист ламалары да, шаманнар да катнаша...».*